| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**05.02.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№192** |

Зеленодольск муниципаль районының эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы каршындагы законсыз эшкуарлыкка каршы тору буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2008 елның 15 маендагы «Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда административ чикләүләрне бетерү буенча кичектергесез чаралар турында» 797нче номерлы Указын, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү эшен оештыру кысаларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районының эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы турында» 2518 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районының эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы каршындагы законсыз эшкуарлыкка каршы тору буенча ведомствоара эшче төркем составыннан Зеленодольск шәһәре прокуроры ярдәмчесе Р.Ш. Муллануровны чыгарырга.
2. Әлеге карарны ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев